**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

# КАРАРЫ

**чираттан тыш утырыш**

**«25» декабрь 2025 ел** **№ 11** **Алан авылы**

Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 нче ноябрендәге 114 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 нче ноябрендәге 114 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (29.07.2024 № 129; 01.11.2024 №147карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 2.1 пунктчасын «, билгеләнешен проектлаучы күпфатирлы йорт булган тәгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Теләче
муниципаль районы Алан
авыл җирлеге башлыгы А.Р. Зиннәтов